
# Тема: Боерык фигыльләрнең юклык төре.




**Казан шәһәре Совет районының**
**“175 нче урта гомуми белем мәктәбе”**
**гомуми белем муниципаль учреждениесе**

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Гаязова Энҗе Фәргать кызы**

**2014 нче ел**

## Кадерле   дусларым!

Сез китаплар укырга яратасыз икән. Афәрин!
Мин дә китаплар укырга бик яратам. ”Кояш чыкса – табигать яңара, китап укысаң – күңел агара”, – ди халык. Мин сезгә серле бер китап җибәрәм, ул сезгә ошар дип уйлыйм. Барлык серләрне дә чишә алсагыз, миннән сезгә бүләк булыр.
Уңышлар телим!

Дустыгыз Тапкырҗан.





Бу шигырь юллары сезгә танышмы?
Аларның авторы кем?

Г.Тукай Акбайны, сабыйларны нәрсәгә өнди?

Әйдәле, Акбай, өйрән син, арт аягың белән тор;
Аума, аума! Туп – туры тор, төз утыр, яхшы утыр.



И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә эш.

Әйдәле, Акбай, өйрән син, арт аягың белән тор;
Аума, аума! Туп – туры тор, төз утыр, яхшы утыр.



И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә эш.

Г.Тукай.





**Дәфтәрләрегезгә дөрес һәм матур итеп языгыз!**

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкат-
дәс нәрсә эш.
Габдулла Тукай.

- Бу мәкальләрне беләсезме, ахырын әйтегез!
- Боерык фигыльләрне табыгыз!
- Алар нинди сорауга җавап бирәләр?
- Боерык фигыльнең юклык төре нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?
- Бу очракта басым кая төшә?



***Бүгенге эшне***

***Үзеңне үзең мактама,***

***Сүзне әйтмә,***

***Эшне башлама,***

***башласаң ташлама.*** ***кеше сине макта***

***иртәгегә калдырма.*** ***әйтсәң – кайтм***



# Боерык фигыльнең юклык төре

**Боерык фигыльнең юклык төре** ***-ма, -мә***
**кушымчалары ярдәмендә ясала:**
***эшлә́мә, җырла́ма*.**



**Бу очракта басым юклык кушымчалары алдыннан куела**

# Юклык төрендә языгыз!




укы  укыма

яз  язма

уйна  уйнама

сикер  сикермә

җырла  җырлама

аша  ашама



бәйлә



бәйлә́мә

ела



ела́ма

шу



шу́ма

бар



ба́рма


йөз



йө́змә



Бу малай сезгә ошыймы?
Сез аңа нинди киңәшләр бирер идегез?



- Китапларның почмакларын бөкләмә!
- Битләрен ертма!
- Пычрак кулларың белән тотма!
- Ашаганда китап укыма!
- Китапларыңны тышла!
- Кадерлә!
- Сакла!
- Яратып укы!



# Анам сүзләре.

Китап — киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең,
Ул хөрмәткә бик хаклы,
Кадерлә син китапны.

Почмакларын бөкләмә,
Битләрен дә ертма син,
Керле кул белән аны
Беркайчан да тотма син.

Укы, бәгърем, син аны,
Китапның син дусты бул.
Бик күп сорауларыңа
Җавап биреп торыр ул.

*Хәсән Шабанов.*








# Түземсезлек белән көтеп калам!



**Милли китапханә Кремль урамында урнашкан.**

**Анда 3 миллионнан артык китап бар.**



# Өй эше

**Фигыльнең юклык төрен кулланып, “Китапханәдә үз – үзеңне тоту” кагыйдәләрен язып килегез.**



